ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 1013 29 ноябрь 2018 г.

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Түбән Кама муниципаль районы территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибе турында нигезләмәне раслау турында» 2018 елның 31 июлендә кабул ителгән 604нче карарына үзгәрешләр кертү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт җайга салуы нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль милектә булган җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә һәм җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру Тәртибен раслау турында» 2016 елның 13 августындагы 553 номерлы карары нигезендә, «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы белән, карар бирәм:

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Түбән Кама муниципаль районы территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибе турында нигезләмәне раслау турында» 2018 елның 31 июлендәге 604нче номерлы карарына (алга таба – карар) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карар белән расланган, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру өчен шартнамә төзү хокукына аукцион үткәрү Тәртибенең 14 пунктындагы «б» пунктчасында «мөрәҗәгать итүче мөһере белән расланган» сүзләреннән соң «(мөһер булганда, шулай ук мөһердән файдалану бурычы Федераль закон белән каралган очракта)» сүзләре белән тулыландырырга.

Җитәкче А.Г. Сәйфетдинов